Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре унынчы номерлы «Ромашка» һәрьяктан үстерешле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүчеләрнең

# «Кукмара варислары» көндәлеге

______________________________



## Кадерле дустым!

Без сине искиткеч кызыклы, мавыктыргыч проектта катнашырга чакырабыз. Син маҗаралы урыннарда булып, төрле күргәзмәләрдә катнашып, шәһәребезнең истәлекле, тарихи урыннары белән танышырсың. Күптөрле кызыклы кешеләр белән аралашып, үзебезнең төбәкнең үткәне һәм бүгенгесе турында бик күп мәгълүмат алырсың. Һәркем халкыбызның үткәнен, гореф – гадәтләрен, йолаларын белергә, аларны буыннан – буынга тапшырырга бурычлы.

**Уңышлар сиңа!**

# ЭЧТӘЛЕК


Кукмара шәһәре

Кукмара төбәкне өйрәнү музее

Үзәк балалар китапханәсе

«Галактика» балалар иҗат йорты

Кукмара балалар музыка мәктәбе

Лицей, гимназия, 3 нче номерлы мәктәп, 4 нче номерлы мәктәп, 5 нче номерлы мәктәп

«Зилант» балалар – яшүсмерләр спорт мәктәбе

«Олимп» балалар – яшүсмерләр спорт мәктәбе

Кукмара чаңгы шуу базасы

Җиңү паркы

Нүрминкә елгасы яр буе

Атлас Булатов исемендәге ял паркы

Мәдәният йорты

Кукмара киез итек - киез комбинаты

Кукмара «Хыял» тегү фабрикасы

Кукмара металл савыт – сабалар заводы

«Забава» азык комбинаты

Тимер юл вокзалы




Борын - борын заманда, XVIII гасыр башында, хәзерге Жилой Рудник авылы янында бакыр ятмалары табыла. Бакыр ятмаларын эшкәртү Кукмара поселогы барлыкка килүгә бик зур ярдәм итә. XVIII гасырда Кукмарада сәүдәгәр Әпсәләмов заводы барлыкка килә. Эшчеләр һәм крестьяннар чыгарган бакыр ятмаларыннан заводта ягулык эшләп чыгара башлыйлар.1812 елда булган Ватан сугышында Кукмарадагы бакыр эшкәртү заводы сугышчыларны сугыш кирәк – яраклары белән тәкъмин иткән. 1851 елда заводта янгын була, ул ябыла. Авыл — Рус Кукмарасы исемен ала. Биредә бакыр савыт – саба эшләп чыгара башлыйлар.

Кукмара бик матур урында урнашкан. А. П. Котельников тәкъдиме буенча тау битләренә агач үсентеләре утыртырта башлыйлар. Шуннан соң һәр елны авыл халкы тау битләренә агачлар утыртуны традициягә кертә .



Кукмара исеме  ике  мари дигән  сүздән алынган. «Кок»  ике  һәм «мари» — кеше.






Халык саны – 2020 елда 17 200 кеше

Милли составы:
татарлар - 81,1%,
удмуртлар - 8,9%,
руслар - 8,0%









Кукмараның сайты  [kukmor.tatarstan.ru](kukmor.tatarstan.ru)

# Кукмара төбәкне өйрәнү музее



Музей 1995 елның  8 маенда ачылган



Музейда Кукмара районының үткәне турында күп мәгълүмат тупланган. Бер залда археологик табылдыклар куелган: анда мамонт, борынгы кешеләрнең сөякләре, көнкүреш әйберләре бар. Кукмара җирлегендә яшәүче  рус, татар, удмурт, мари халыкларының тормышы турында да бик күп материал тупланган. Музей ишегалдына керүгә сезне Убырлы карчык, Шүрәле персонажлары каршы алыр.









## Минем тәэсирләрем

Адрес: ТР,  Кукмара шәһәре,
Ленин урамы, 8 йорт

# Балалар китапханәсе



Китапханәдә һәрвакыт бик күп кызыклы китаплар табарга мөмкин. Яңа китаплардан күргәзмәләр оештырыла.



Һәр елны «Укучылар көне» билгеләп үтелә.



Уку залында мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен аерым почмак бар, анда матур рәсемнәр белән бизәлгән китаплар табарга була.





## Минем тәэсирләрем

Адрес: ТР, Кукмара шәһәре,
Ленин урамы, 36 йорт

## «Галактика» балалар иҗат йорты







Биш юнәлеш буенча түгәрәкләр алып барыла:
туган якны өйрәнү, хәрби - патриотик, нәфис - нәфасәти, экология - биология, фәнни - техник. Укыту татар һәм рус телләрендә алып барыла. Түгәрәкләрдә 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге 1287 бала шөгыльләнә.

## Кукмара балалар сәнгать мәктәбе





**Бу мәктәпкә эләккән балага бервакытта да күңелсез булмаячак: анда төрле рәсемнәр ясарга, биергә, җырларга, артистлык осталыгына өйрәнергә мөмкин. Монда һәрвакыт күңелле музыка, балаларның шат авазлары ишетелеп тора.**

Минем тәэсирләрем

Адрес: ТР, Кукмара шәһәре,
Ленин урамы, 31 йорт

# Кукмара музыка мәктәбе




















## *Минем тәэсирләрем*

Адрес: ТР, Кукмара шәһәре,
М.Җәлил урамы, 4 йорт

# Исәнме, мәктәп!


Гимназия


Лицей


3нче номерлы мәктәп


4 номерлы мәктәп


5номерлы мәктәп


Зур Кукмара мәктәбе




## Минем тәэсирләрем

# «Зилант» балалар – яшүсмерләр спорт мәктәбе

















Бу спорт мәктәбендә Татарстанда гына түгел, Россиягә, бөтен дөньяга билгеле спортчылар тәрбияләнә.



*Минем тәэсирләрем*







Адрес: ТР, Кукмара шәһәре,
Ленин урамы, 34 йорт

# «Олимп» балалар – яшүсмерләр спорт мәктәбе




Кечкенәдән хоккей, фигуралы шуу белән шөгыльләнү балаларда сәламәт яшәүгә кызыксыну тәрбияли. Алга таба зур максатлар куярга этәргеч ясый.





Монда шөгыльләнүчеләр төрле шәһәрләргә барып, көч сынашып үзләрен сыныйлар, күренекле спортчылар белән танышалар.





## Минем тәэсирләрем

Адрес: ТР, Кукмара шәһәре,
Ленин урамы, 37 Б йорт



# Кукмара таудан шуу базасы




Таудан шуу базасында кыш буе кеше өзелеп тормый. Монда хәтта республика буенча да төрле кышкы спрот төрләре буенча ярышлар уздырыла





XX гасыр урталарында монда яшәүчеләр тау битләренә агач үсентеләре утырта башлаганнар, хәзер инде ул зур урманга әйләнде. Таудан шуу базасы Кукмара кунакларының яраткан урынына әйләнде. Монда төрле районнардан, шәһәрләрдән килеп ял итәләр. Бу таулар Кукмара шәһәренең горурлыгы булып тора.




## Минем тәэсирләрем



Адрес: ТР, Кукмара шәһәре

# Җинү паркы





Кукмара шәһәренең үзәгендә урнашкан Җиңү паркы барлык кешеләрнең яраткан ял итү урынына әйләнде. Монда шәһәребезнең бәйрәмнәре зурлар билгеләп үтелә.








## *Минем тәэсирләрем*







# Нүрминкә яр буе








Соңгы елларда төзелгән истәлекле урыннарның берсе – Нүрминкә яр буе. Кыска гына вакыт эчендә ул балаларның да, өлкәннәрнең дә яраткан урынына әйләнде. Яр буйлап сузылган эскәмияләр, күперчекләр агачтан эшләнгән. Монда амфитеатр, сәхнә бар. Кич белән яр буен якты утлар яктырта. Көндез дә, кич белән дә рәхәтләнеп ял итәргә мөмкин.










## *Минем тәэсирләрем*

Адрес: ТР, Кукмара шәһәре

# Атлас  Булатов исемендәге ял паркы





2015 нсе елда Атлас Булатов исемендәге ял паркы ачылды. Бу  гаилә белән ял итү өчен бик яхшы урын. Кечкенәләр өчен атынгычлар, уен мәйданчыклары бар. Төрле бәйрәмнәр уздырыла. Кыш көне чаңгыда шуарга, җәй көне башка спорт төрләре белән шөгыльләнергә мөмкин.



## Минем тәэсирләрем







Адрес:  ТР, Кукмара шәһәре

# Мәдәният йорты



Хәзерге вакытта мәдәният йортында 3 хореографик коллектив, төрле татар һәм рус җырлары ансамбльләре, яшьләр театр студиясе, «Нүрминкә бизәкләре» дигән фольклор коллективы, «Баламишкин» исемендәге гармунчылар ансамбле эшләп килә. Мәдәният йортында эшләүчеләр шәһәребездә үтә торган барлык бәйрәмнәрне оештыручылар булып тора.









## Минем тәэсирләрем

Адрес: ТР, Кукмара шәһәре,
Ленин урамы, 38 йорт

# Кукмара киез – итек киез комбинаты

1867 нчы елда сәүдәгәр Бертуган Комаровлар нигез салган.




Кукмара киез - итек киез комбинаты бөтен Россиягә билгеле. Комбинат елга 1 миллионнан артык пар киез аяк киеме эшләп чыгара. Аяк киеменнән тыш, монда тагын бик күп төрле продукция эшләп чыгаралар: юрганнар, жилетлар, өйдә кия торган чүәкләр, кышкы аяк киемнәре. Болар барысы да жылы, эшкәртелгән йоннан эшләнгән сыйфатлы әйберләр.










## *Минем тәэсирләрем*

Адрес: ТР, Кукмара шәһәре,
Вахит урамы, 1 йорт

# Кукмара тегү фабрикасы




Кукмара тегү фабрикасы 1956 елдан бирле эшли. Фабрика балалар һәм өлкәннәр өчен кышкы, язгы, көзге курткалар, плащлар тегә. Анда тегелгән киемнәрне башка төбәкләрдән килеп тә алалар. Чөнки алар бик сыйфатлы һәм матур.







## Минем тәэсирләрем

Адрес: ТР, Кукмара шәһәре,
Эшчеләр тыкрыгы урамы, 1 йорт

# Кукмара  металл  савыт - сабалар заводы




Заводның тарихы 1743 нче елларга барып тоташа. Башта завод бакыр кою заводы булган. Заводка Семен  Еремеев –Иноземцев дигән сәүдәгәр нигез салган.   XIX гасыр башында монда  700 кеше эшли.  Күп еллар завод үзенең эшен туктатып тора.

1930 нче елда заводта  металл  савыт – сабалар эшли башлыйлар.  1940 нчы елда кою цехы ачыла.  1940-45 нче елларда завод фронтка бик күп товарлар эшләп җибәрә. 1950 нче елда  алюмин савыт – сабалар эшләп чыгара башлыйлар.  1967 нче елдан  завод  «Кукмара  металл савыт –сабалар заводы» дигән исем  астында эшли башлый.

## *Минем тәэсирләрем*







Адрес: ТР, Кукмара шәһәре,
Ленин урамы,  154 йорт

# «Забава» азык комбинаты


«Забава» исемен йөртүче азык комбинаты үзенең тәмле лимонады белән тирә – якка билгеле. Чөнки монда чыккан тәмле суны хәтта башка районнардан, шәһәрләрдән килеп алалар. Анда тагын бик күп төрле тәмле прәннекләр, печеньелар пешерәләр.

«Кукморский» печәте сугылган лимонадны олылар да, кечкенәләр дә ярата.












Минем тәэсирләрем

Адрес: ТР, Кукмара шәһәре,
Ленин урамы, 1 йорт

# Кукмара тимер юл вокзалы

Кукмара вокзалдан башлана!



Тимер юлның Кукмара уртасыннан узуына Бертуган Комаровларның катнашы бар дигән сүзләр йөри. Алар шулай итеп үзләренең фабрикада эшләнгән товарларын тимер юл аша төрле төбәкләргә җибәргәннәр.










## Минем тәэсирләрем

# 10 нчы номерлы «Ромашка» балалар бакчасы

Шәһәр буенча сәяхәт иту сезгә ошадымы?





Үзеннең дусларыңны син кайларга чакырыр идең?




Үсеп житкәч кем булырга телисең?



Нинди һөнәрләр белән син якыннан таныштың?





Син тагын кайларга барыр идең?